РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
МЕЛЛЯ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘЛЛӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423989, Р.Т. Муслюмовский район, с.Мелля-Тамак, ул. Кооперативная д.45а*
Mtamak.Mus@tatar.ru_ *тел. (8-85556) 3-01-35*
ИНН 1629004026, КПП 162901001, ОГРН 1061687005324, ОКАТО 92242830000.

---

Мәллә-Тамак авылы 27 сентябрь 2021ел

**КАРАР № 19**

**«Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газоннарны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 июлендәге 13 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газоннарны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 июлендәге 13 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән расланган Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газоннарны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.1. пунктының 2 пунктчасында «агачлар, куакларның авариясе турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунктның дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4. пунктны төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «Башкарма комитет яки төзелгән килешү нигезендә муниципаль район җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга.;

1.5. 2.6.1 пунктның 6, 11 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.6.3.пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктның 2 пунктчасындагы «яисә гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә, һичшиксез бетерелергә тиеш (авария хәлендәге агачлар) яшел үсентеләрне сүтү заруриылыгы расланмаганда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында «(авария-торгызу эшләрен башкаруга яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен бик кирәк булган очраклардан тыш (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 3.4.2. пунктның 4 абзацындагы «шулай ук авария-торгызу эшләрен үткәрү өчен яисә һичшиксез бетерелү зарурлыгы булган хәлдәге яшел утыртмаларны бетерү (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) өчен яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3. пунктны төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5.пункттагы «гариза бирүче авария-торгызу эшләрен үткәрү яисә һичшиксез бетерелү зарурлыгы булган хәлдәге яшел утыртмаларны бетерү кирәк булганда (агачның, авария хәлендәге агачларның аву куркынычын бетерү өчен) муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта – ике эш көне.» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. регламентның 2 нче кушымтасында «Авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Мәллә-Тамак авыл җирлеге җитәкчесе Х.М.Хусаенов